**МИНИСТЕРСТВО ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ УРМАН ХУҖАЛЫГЫ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

26.12.2023 № 610-осн

Казан шәһәре

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Бюджет кодексының $47^2$ статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 маендагы 393 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карарлар кабул итү тәртибенә карата гомуми таләпләр нигезендә боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итүнең кушымтада бирелгән тәртибен расларга.
2. Юридик бүлек җитәкчесе Т.А.Барсуковага әлеге боерыкның Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән срокта Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында дәүләт теркәвенә алынуын тәэмин итәргә.
3. Боерык үтәлешен тикшереп торуны министр урынбасары Р.К.Гомәровка йөкләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының
26.12.2023 № 610-осн боерыгы
белән расланды

Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибе

1. Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итүнең әлеге Тәртибе (алга таба – Тәртип) Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык) тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану процедурасын билгеләү максатларында эшләнде.

2. Министрлык тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү өчен нигез булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче – физик затның үлеме яки аны Россия Федерациясе законнары нигезендә үлгән дип игълан итү;

2.2. Шәхси эшкуар – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның мөлкәте җитәрлек булмау сәбәпле Татарстан Республикасы бюджетына түләнмәгән бурычы өлешендә «Бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турында» 2002 елның 26 октябрендәге 127-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 127-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә банкрот дип танылганда.

Банкротлык фактын раслаучы документ булып конкурс эшчәнлеген тәмамлау яисә шәхси эшкуар булып торган гражданин – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд акты, шулай ук Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан үзен бөлген (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә физик зат – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ тора;

2.3. Шәхси эшкуар булмаган гражданинны 127-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә банкрот дип тану – әлеге Федераль закон нигезендә кредиторлар белән исәп-хисаплар тәмамланганнан соң Татарстан Республикасы бюджетына түләнмәгән түләүләр буенча бурычы өлешендә;

2.4. Оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле Татарстан Республикасы бюджетына түләнмәгән түләүләр буенча бурычы өлешендә оешма – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче зат бетерелгән очракта;

2.5. Штраф рәвешендә җәзага хөкем ителгән затларга карата амнистия турында яки ярлыкау турында актлар кулланылганда яки бюджет керемнәре администраторы

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләттерү мөмкинлеген югалта торган суд карары кабул ителгәндә;

2.6. Суд приставы-башкаручы тарафыннан «Башкару эшчәнлеге турында» 2007 елның 2 октябрендәге 229-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 229-ФЗ номерлы федераль закон) 46 статьясындагы 1 өлешендәге 3 һәм 4 пунктында каралган нигезләр буенча башкару эшчәнлегенең тәмамлануы һәм түләттерүчегә башкару документын кире кайтару турында карар чыгарылганда, әгәр бурычның барлыкка килү датасыннан башлап өч елдан күбрәк вакыт узса, түбәндәге очракларда:

бурыч күләме бурычлы затка карата банкротлык турында эш кузгату өчен бөлгенлеккә төшү (банкротлык) турындагы Россия Федерациясе законында билгеләнгән таләпләр күләменнән артып китмәгәндә;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүчене банкрот дип тану турында гариза суд тарафыннан кире кайтарылганда яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эш туктатылганда;

2.7. Теркәүгә ала торган орган тарафыннан юридик зат Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдырылганда (ул Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә белән раслана) һәм, 229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктында каралган нигез буенча башкару документын түләттерүче затка кайтарып, башкару эшчәнлеген туктату турында суд пристав-башкаручысы тарафыннан элегрәк чыгарылган карар булганда, – оешманың мөлкәте җитәрлек булмау һәм (яки) әлеге оешманы гамәлгә куючылар (катнашучылар) тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән чикләрдә һәм тәртиптә түләү мөмкинлеге булмау сәбәпле Татарстан Республикасы бюджетына түләнмәгән түләүләр буенча бурыч өлешендә.

«Юридик затларны һәм шәхси эшкуарларны дәүләт теркәвенә алу турында» 2001 елның 8 августындагы 129-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә теркәүгә алучы органның юридик затны Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан төшереп калдыру турында карары гамәлдән чыккан дип танылган очракта, Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча әлеге пунктча нигезендә элегрәк түләтү өчен өметсез дип танылган бурыч бюджет (бухгалтерлык) исәбендә торгызылырга тиеш.

3. Тәртипнең 2 пунктында каралган очраклар белән беррәттән, түләнмәгән административ штрафлар, әгәр административ җәза билгеләү турында карар чыгарган судья, орган, вазыйфаи зат тарафыннан Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексында каралган очракларда, административ җәза билгеләү турындагы карар үтәлешен туктату турында карар чыгарылган булса, түләттерү өчен өметсез дип таныла.

4. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар түбәндәге документлар нигезендә кабул ителә:

4.1. Әлеге Тәртипнең 1 нче кушымтасына ярашлы форма буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләү буенча исәпкә алына торган бурычлар суммалары турында бюджет керемнәре администраторы хисаплылыгыннан өземтә;

4.2. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүне тәэмин итү буенча кабул ителгән чаралар турында Министрлык белешмәләре;

4.3. Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану очракларын раслаучы документлар, шул исәптән:

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче – физик затның үлемен раслаучы яки аны үлгән дип игълан итү фактын раслаучы документ (Тәртипнең 2 пунктының 2.1 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

конкурс эшчәнлеген тәмамлау яисә шәхси эшкуар булып торган гражданин – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның мөлкәтен сатуны төгәлләү турында суд акты, шулай ук Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан үзен бөлген (банкрот) дип тану турында суд акты кабул ителүгә бәйле рәвештә физик зат – Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затның шәхси эшкуар сыйфатында эшчәнлеген туктатуы турындагы белешмәләрне үз эченә алган документ (Тәртипнең 2 пунктындагы 2.2 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче гражданинның (Тәртипнең 2 пунктының 2.3 пунктчасында күрсәтелгән очракта) конкурс производствосын тәмамлау яисә мөлкәтен сатуны тәмамлау турында суд акты;

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче оешманы бетерү белән бәйле рәвештә эшчәнлеген туктату турында мәгълүматлар булган документ (Тәртипнең 2 пунктындагы 2.4 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

штраф яки суд акты рәвешендә хөкем ителгәннәргә карата амнистия яки кичерү турында акт, аның нигезендә бюджет керемнәре администраторы Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтү мөмкинлеген югалта (Тәртипнең 2 пунктының 2.5 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

229-ФЗ номерлы федераль законның 46 статьясындагы 1 өлешенең 3 яки 4 пунктларында каралган нигез буенча җәзага тартылучыга башкарма документны кайтару белән бәйле рәвештә башкарма производствоны тәмамлау турында суд приставы-башкаручысы карары (Тәртипнең 2 пунктының 2.6 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче затны бөлген (банкрот) дип тану турында гаризаны кире кайтару турында яисә банкротлык турында эштә кулланыла торган процедураларны үткәрүгә суд чыгымнарын каплау өчен җитәрлек күләмдә акча булмау сәбәпле банкротлык турындагы эшне туктату турында суд акты (Тәртипнең 2 пунктындагы 2.6 пунктының өченче абзацында күрсәтелгән очракта).

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр түләүче юридик затны теркәү органы карары буенча күрсәтелгән реестрдан чыгару турында Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан мәгълүматлар булган документ (Тәртипнең 2 пунктындагы 2.7 пунктчасында күрсәтелгән очракта);

административ җәза билгеләү турындагы карарны үтәүне туктату турында карар (Тәртипнең 3 пунктында күрсәтелгән очракта).

5. Бурычны өметсез дип тану эшен оештыру максатыннан, Комиссия рәисе, Комиссия рәисе урынбасары һәм Комиссия әгъзалары составында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны исәптән чыгару комиссиясе (алга таба – Комиссия) төзелә. Комиссиянең шәхси составы министр (аның вазифаларын башкаручы зат) (алга таба – министр) боерыгы белән раслана.

6. Комиссия рәисе:

Комиссия эшенә җитәкчелек итә;

Комиссия утырышларын үткәрә;

Комиссия әгъзалары арасыннан Комиссиянең җаваплы секретарен билгели.

Рәис булмаганда аның функцияләрен Комиссия рәисе урынбасары башкара.

7. Комиссиянең җаваплы сәркатибе:

- Комиссия эшчәнлеген алып баруны оештыра;

- Комиссия әгъзаларын Комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында мәгълүмат белән тәэмин итә;

Комиссия рәисе күрсәтмәсе буенча Комиссия эшенә бәйле башка функцияләрне башкара.

8. Комиссия утырышлары кирәк булган саен, әмма елына кимендә бер тапкыр үткәрелә.

9. Тәртипнең 4 пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану нигезләрен раслаучы документлар пакеты Министрлыкка Тәртипнең 2 яки 3 пунктларында каралган очрак турында мәгълүмат кергәндә Министрлыкның икътисад, дәүләт заказын урнаштыру һәм түләүләр белән идарә итү бүлеге тарафыннан формалаштырыла. Документлар Комиссиягә карау өчен квартал саен җибәрелә.

10. Комиссия Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычны түләтү өчен өметсез дип тану яки танудан баш тарту турында карарны аның утырышта катнашучы әгъзалары саныннан гади күпчелек тавыш белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул итә. Тавышлар тигез булганда, утырышта рәислек итүченең тавышы хәл итүче дип санала.

11. Комиссия карары Комиссия утырышы уздырылганнан соң ун эш көне эчендә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымтага ярашлы форма буенча түбәндәге мәгълүматны үз эченә алган акт белән рәсмиләштерелә:

оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта);

салым түләүченең идентификацияләү номеры, төп дәүләт теркәвенә алу номеры, салым түләүченең оешмасын исәпкә алуның сәбәп коды (физик зат – салым түләүченең идентификацияләү номеры) (булган очракта);

аның буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүдә бурыч барлыкка килгән белешмәләр;

аның буенча Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурыч исәпкә алына торган Татарстан Республикасы бюджеты керемнәрен классификацияләү коды, аның исеме;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычлар суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына тиешле түләүләр буенча пенялар һәм штрафлар буенча бурыч суммасы;

Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул ителгән көн.

Акт ике нөсхәдә төзелә һәм утырышта рәислек итүче һәм утырышта булган Комиссия әгъзалары тарафыннан имзалана.

Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры урынбасары тарафыннан расланган Акт Татарстан Республикасы бюджетына түләүләр буенча бурычларны бюджет (бухгалтерлык) хисабында исәптән чыгару өчен нигез булып тора.

Татарстан Республикасы бюджетына
Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы
министрлыгы тарафыннан идарә ителә
торган түләүләр буенча бурычларны
түләтүгә өметсез дип тану турында карар
кабул итү тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган, Татарстан Республикасы бюджетына түләүләрне түләү буенча исәпкә алына торган бурыч суммалары турында Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы хисаплылыгыннан өземтә

______________________________________________________________

(оешманың тулы исеме, ИНН/КПП, ОГРН, физик затның фамилиясе,
исеме, атасының исеме (булган очракта), ИНН)

____ елга булган торышында

| т/с | КБК | Түләүнең исеме | Бурычның барлыкка килү датасы (вакыты) | Бурыч суммасы, сум |
|---|---|---|---|---|
| | | | | |
| | | | | |

______________________________ ____________/______________________/

ТР Урман хуҗалыгы министрлыгының
структур бүлекчә башлыгының ФИА (булган очракта) имзасы

Татарстан Республикасы бюджетына
Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында карар кабул итү тәртибенә 2 нче кушымта

Форма

Раслыйм
Татарстан Республикасы урман хуҗалыгы министры урынбасары
________________________
(имза) (Ф.И.А. (булган очракта)
«__» ________ 20__ ел.

**Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы тарафыннан идарә ителә торган түләүләр буенча бурычларны түләтүгә өметсез дип тану турында**
**№____ АКТ**

«___»_________ 20__ ел. Казан шәһәре

Тәкъдим ителгән документлар нигезендә активларны кертү һәм чыгару буенча Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы комиссиясе
__________________________________________________________________*
бурычларны түләтүгә өметсез дип тану мәсьәләсен карады
__________________________________________________________________
(оешманың тулы исеме (физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта)),
__________________________________________________________________
салым түләүченең идентификацион номеры, төп дәүләт теркәү номеры,
__________________________________________________________________
(физик зат – салым түләүченең идентификацион номеры)) Татарстан Республикасы бюджетына түләү буенча
__________________________________________________________________
(бурыч барлыкка килгән түләү турында мәгълүмат**, аның буенча бурыч исәпкә алына торган КБК,
__________________________________________________________________
аның исеме)
әлеге түләүләр буенча бурычлар суммасы – ________________________,
әлеге түләүләр буенча бурычлар суммасы – ________________________,
Комиссия карар кабул итте:

_______________________________________________________________

_______________________________________________________________

________________________________________________________________

Акт 2 данәдә төзелде

Комиссия рәисе: ______________________ ___________________
(Ф.И.А. (булган очракта) (имза)

Комиссия әгъзалары: ___________________ ______________________
_________________________________________
(Ф.И.А. (булган очракта) (имза)

___________________ ______________________
(Ф.И.А. (булган очракта) (имза)

__________________ _______________________
(Ф.И.А. (булган очракта) (имза)

__________________ _______________________
(Ф.И.А. (булган очракта) (имза)

______________________________________________

***** - документларның исемнәре һәм реквизитлары күрсәтелә.

****** - бурыч барлыкка килгән түләүнең исеме, таләпләр куелган документларның (карарлар, башка) исемнәре һәм реквизитлары күрсәтелә.